СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советы КАРАРЫ

2020 елның 3 ноябре №2-11

"Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алмашлы керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлдән чыгару турында»

2012 елның 29 июнендәге "Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм "Банклар һәм банк эшчәнлеге турында" Федераль законның 26 статьясына үзгәрешләр кертү турында" 97-ФЗ номерлы Федераль закон (2016 елның 2 июнендә кертелгән үзгәрешләр белән) нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2012 ел, 2 ноябрьдәге 15-125 нче номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алмашлы керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлгә кертү турында» карарын 2021 елның 1 гыйнвареннән үз көчен югалткан дип санарга.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2016 елның 10 ноябрендәге 19-95 номерлы "Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2012 елның 2 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алмашлы керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлгә кертү турында" карарына үзгәрешләр кертү турында"гы карарын 2021 елның 1 гыйнвареннән үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы В.М. Козлов